СОВЕТ
АПАЗОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д. 23, с. Апазово,
Арский муниципальный район, 422006

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АПАЗ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 23 йорт, Апаз авылы,
Арча муниципаль районы, 422006

Тел. (84366)3-92-40, факс (84366)3-92-40. E-mail: Apaz.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы**
**Апаз авыл җирлеге Башлыгы**
**КАРАРЫ**

**“02” ноябрь 2023 ел** **№ 7**

**Татарстан Республикасы**
**Арча муниципаль районы**
**"Апаз авыл җирлеге"**
**муниципаль берәмлегенең**
**җирдән файдалану һәм төзелеш**
**кагыйдәләре проекты буенча**
**гавами тыңлаулар билгеләү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31 - 33 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы, 2022 елның 04 августындагы 79 нчы номерлы Апаз авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлегендә гавами тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә нигезендә, авыл җирлегендә яшәүчеләрнең гавами тыңлаулар үткәрү юлы белән проектны тикшерүдә катнашу хокукын үтәү максатыннанн, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Апаз авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты (алга таба — Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты) буенча гавами тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

2.1. гавами тыңлаулар үткәрүне оештыручы - Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү буенча комиссия (алга таба-Комиссия);

2.2. гавами тыңлауларны үткәрү вакыты һәм урыны:

2023 елның 03 декабрендә, 10.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Арча районы, Апаз авылы, Совет урамы, 19 йорт адресы буенча Апаз мәдәният йортында;

2.3. җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертелә торган адрес - 422006, Татарстан Республикасы, Арча районы, Апаз авылы, Совет урамы, 23 нче йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге башкарма комитеты бинасы (дүшәмбе — җомга 8-00 сәгатьтән 12-00 сәгатькә кадәр һәм 13-00 сәгатьтән 16-00 сәгатькә кадәр, төшке аш 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр).

2.4. җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектының демонстрацион материаллары күргәзмә-экспозициясен оештыру - Апаз авыл җирлегендә яшәүчеләргә җиткерү максатыннан Татарстан Республикасы, Арча районы, Апаз авылы, Совет урамы, 19 нчы йорт адресы буенча урнашкан Апаз мәдәният йорты бинасында (дүшәмбе-җомга 8-00 сәгатьтән 12-00 сәгатькә кадәр һәм 13-00 сәгатьтән 16-00 сәгатькә кадәр, төшке аш 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр).

3. Комиссиягә:

3.1. билгеләнгән тәртипкә ярашлы рәвештә һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлауларны әзерләргә һәм үткәрергә;

3.2. гавами тыңлаулар үткәрү нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Арча район Советына гавами тыңлаулар беркетмәсен, гавами тыңлаулар тәкъдимнәрен, гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен, шулай ук җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең эшләнгән (үзгәрешләр кертү очрагында) проектын тапшырырга;

3.3. 2023 нче елның 07 декабренә кадәр җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Интернет челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (www.arsk.tatarstan.ru).

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (www.pravo.tatarstan.ru), Арча муниципаль районының рәсми сайтында (www.arsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Апаз авыл җирлеге башлыгы Р.Ф.Котдусов